МИНИСТЕРСТВО ЭКОНОМИКИ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ИКЪТИСАД МИНИСТРЛЫГЫ

**ПРИКАЗ** **БОЕРЫК**

24.05.2019 Казан ш. № 245

«Юридик затларның аерым төрләре тарафыннан товарлар, эшләр, хезмәт күрсәтүләр сатып алу турында» 2011 елның 18 июлендәге 223-ФЗ номерлы федераль закон нигезендә Россия Федерациясе Хөкүмәте билгеләгән заказчылар тарафыннан товарлар, эшләр, хезмәт күрсәтүләр сатып алу гамәлгә ашырылганда тәминатчылар (башкаручылар, подрядчылар) сыйфатында алар үсешенә этәргеч бирү максатларында кече һәм урта эшкуарлык субъектларына финанс, мөлкәт, мәгълүмат, маркетинг һәм башка төр ярдәм күрсәтү буенча төбәкнең квалификация комиссиясе эшчәнлеге регламентын раслау турында

«Юридик затларның аерым төрләре тарафыннан товарлар, эшләр, хезмәт күрсәтүләр сатып алу турында» 2011 елның 18 июлендәге 223-ФЗ номерлы федераль закон нигезендә Россия Федерациясе Хөкүмәте билгеләгән заказчылар тарафыннан товарлар, эшләр, хезмәт күрсәтүләр сатып алу гамәлгә ашырылганда тәминатчылар (башкаручылар, подрядчылар) сыйфатында алар үсешенә этәргеч бирү максатларында кече һәм урта эшкуарлык субъектларына финанс, мөлкәт, мәгълүмат, маркетинг һәм башка төр ярдәмне күрсәтү мәсьәләләре буенча «КУЭ» корпорациясе» АҖ директорлар советы карары (2018 елның 26 декабрендәге 68 номерлы беркетмә) белән расланган методик киңәшләргә ярашлы рәвештә **боерык бирәм:**

1. Әлеге боерык кушымтасына ярашлы рәвештә «Юридик затларның аерым төрләре тарафыннан товарлар, эшләр, хезмәт күрсәтүләр сатып алу турында» 2011

елның 18 июлендәге 223-ФЗ номерлы федераль закон нигезендә Россия Федерациясе Хөкүмәте билгеләгән заказчылар тарафыннан товарлар, эшләр, хезмәт күрсәтүләр сатып алу гамәлгә ашырылганда тэминатчылар (башкаручылар, подрядчылар) сыйфатында алар үсешенә этәргеч бирү максатларында кече һәм урта эшкуарлык субъектларына финанс, мөлкәт, мәгълүмат, маркетинг һәм башка төр ярдәм күрсәтү буенча төбәкнең квалификация комиссиясе эшчәнлеге регламентын расларга.

2. Әлеге боерык үтәлешен контрольдә тотуны министрның беренче урынбасары – Эшкуарлыкны һәм конкуренцияне үстерү департаменты директоры Р.Р.Сибгатуллинга йөкләргә.

**Министр** **Ф.С. Габделганиев**

Татарстан Республикасы
Икътисад министрлыгының
24.05.2019 № 245
боерыгына кушымта

**«Юридик затларның аерым төрләре тарафыннан товарлар, эшләр, хезмәт күрсәтүләр сатып алу турында» 2011 елның 18 июлендәге 223-ФЗ номерлы федераль закон нигезендә Россия Федерациясе Хөкүмәте билгеләгән заказчылар тарафыннан товарлар, эшләр, хезмәт күрсәтүләр сатып алу гамәлгә ашырылганда тэминатчылар (башкаручылар, подрядчылар) сыйфатында алар үсешенә этәргеч бирү максатларында кече һәм урта эшкуарлык субъектларына финанс, мөлкәт, мәгълүмат, маркетинг һәм башка төр ярдәм күрсәтү буенча төбәкнең квалификация комиссиясе эшчәнлеге регламенты**

## 1. Гомуми нигезләмәләр

1.1. Әлеге Регламент «Юридик затларның аерым төрләре тарафыннан товарлар, эшләр, хезмәт күрсәтүләр сатып алу турында» 2011 елның 18 июлендәге 223-ФЗ номерлы федераль закон нигезендә Россия Федерациясе Хөкүмәте билгеләгән заказчылар тарафыннан товарлар, эшләр, хезмәт күрсәтүләр сатып алынганда тэминатчылар (башкаручылар, подрядчылар) сыйфатында алар үсешенә этәргеч бирү максатларында кече һәм урта эшкуарлык субъектларына финанс, мөлкәт, мәгълүмат, маркетинг һәм башка төр ярдәм күрсәтү буенча төбәкнең квалификация комиссиясенең (алга таба – ТКК) функцияләрен, вәкаләтләрен, аны формалаштыру һәм аның эшчәнлек тәртибен билгели.

1.2. ТКК Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгы боерыгы белән формалаштырыла һәм «Юридик затларның аерым төрләре тарафыннан товарлар, эшләр, хезмәт күрсәтүләр сатып алу турында» 2011 елның 18 июлендәге 223-ФЗ номерлы федераль закон нигезендә Россия Федерациясе Хөкүмәте билгеләгән заказчылар тарафыннан товарлар, эшләр, хезмәт күрсәтүләр сатып алу гамәлгә ашырылганда тэминатчылар (башкаручылар, подрядчылар) сыйфатында алар үсешенә этәргеч бирү максатларында кече һәм урта эшкуарлык субъектларына (алга таба – КУЭ), шулай ук производствосы Россия Федерациясе территориясендә

урнашкан, шул исәптән чит ил катнашындагы, башка төр эре компанияләргә финанс, мөлкәт, мәгълүмат, маркетинг һәм башка төр ярдәм күрсәтүгә юнәлдерелгән чараларны (алга таба тиешенчә – «үстерү» чаралары, заказчылар) тормышка ашыру кысаларында килешенгән карарлар кабул итү өчен төзелгән махсус тулы вәкаләтле коллегиаль орган булып тора.

1.3. ТКК «үстерү» чараларын гамәлгә ашыру кысаларында Россия Федерациясе Конституциясенә, «Юридик затларның аерым төрләре тарафыннан товарлар, эшләр, хезмәт күрсәтүләр сатып алу турында» 2011 елның 18 июлендәге 223-ФЗ номерлы, «Конкуренцияне яклау турында» 2006 елның 26 июлендәге 135-ФЗ номерлы, «Россия Федерациясендә кече һәм урта эшкуарлыкны үстерү турында» 2007 елның 24 июлендәге 209-ФЗ номерлы федераль законнарга, башка закон актларына, федераль башкарма хакимият органнары норматив хокукый актларына, Татарстан Республикасы закон актларына, Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органнары норматив хокукый актларына, Татарстан Республикасы законнарына, әлеге Регламентка таянып эш итә, «Юридик затларның аерым төрләре тарафыннан товарлар, эшләр, хезмәт күрсәтүләр сатып алу турында» 2011 елның 18 июлендәге 223-ФЗ номерлы федераль закон нигезендә Россия Федерациясе Хөкүмәте билгеләгән заказчылар тарафыннан товарлар, эшләр, хезмәт күрсәтүләр сатып алу гамәлгә ашырылганда тэминатчылар (башкаручылар, подрядчылар) сыйфатында алар үсешенә этәргеч бирү максатларында кече һәм урта эшкуарлык субъектларына финанс, мөлкәт, мәгълүмат, маркетинг һәм башка төр ярдәм күрсәтү мәсьәләләре буенча «КУЭ» корпорациясе» АҖ директорлар советы карары (2018 елның 26 декабрендәге 68 номерлы беркетмә) белән расланган методик киңәшләрне эшендә куллана.

1.4. ТКК эшчәнлеген оештыру-техник тәэмин итү төбәкнең компетенцияләр үзәге (алга таба – ТКҮ) тарафыннан гамәлгә ашырыла. ТКҮ функцияләре Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2014-2021 елларга Татарстан Республикасының икътисадый үсеше һәм инновацион икътисады» дәүләт программасын раслау турында» 2013 елның 13 октябрендәге 823 номерлы карары

белән расланган «2018-2021 елларга Татарстан Республикасында кече һәм урта эшкуарлыкны үстерү» ярдәмче программасы нигезендә «Кама инновацион территориаль-җитештерү кластеры» коммерциясез партнерлыгы» ассоциациясе тарафыннан гамәлгә ашырыла.

## 2. ТКК функцияләре

2.1. ТКК түбәндәге функцияләрне башкара:

2.1.1. Заказчылар тарафыннан товарлар, эшләр, хезмәт күрсәтүләр сатып алынганда тәэминатчылар (башкаручылар, подрядчылар) сыйфатында катнашучы КУЭ субъектлары үсешенең өстенлекле юнәлешләрен билгели.

2.1.2. КУЭ субъектларын квалификацияле бәяләү методикасын, шул исәптән индивидуаль үсеш картасы формасын һәм структурасын раслый (алга таба – ИҮК).

2.1.3. ТКҮ күрсәтмәсе буенча квалификацияле бәяләү уздыруга КУЭ субъектлары заявкаларын һәм КУЭ субъекты турында белешмәләрне алдан тикшерү нәтиҗәләрен карый.

2.1.4. Квалификацияле бәяләү үткәрү һәм ИҮК формалаштыру турында йә КУЭ субъектына квалификацияле бәяләү үткәрүдән баш тарту сәбәпләрен күрсәтеп, баш тарту турында карар кабул итә.

2.1.5. ТКҮ тәкъдиме буенча ИҮК квалификацияле бәяләү нәтиҗәләрен һәм проектларын карый, ИҮК раслау турында карар кабул итә.

2.1.6. Эшләп бетерү вакытын һәм ИҮК проектын кабат карау датасын билгеләп, ИҮК проектын эшләп бетерү буенча тәкъдимнәр кертә.

2.1.7. «Үстерү» чараларын гамәлгә ашыру һәм аның төп шартлары кысаларында КУЭ субъекты белән ТКҮ хезмәтләр күрсәтү турында шартнамә төзүе турында карар кабул итә.

2.1.8. ИҮК гамәлгә ашыру йомгаклары буенча КУЭ субъектының квалификацияле бәяләү нәтиҗәләрен карый һәм кабул ителгән карар турында Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгына мәгълүмат җибәрә.

2.1.9. Заказчыларда ихтыяҗ зур булган номенклатура буенча продукция чыгара ала торган КУЭ субъектлары исемлеген төзүдә һәм мондый заказчылар өчен товарлар, эшләр, хезмәт күрсәтүләр белән тәэмин итеп торуда катнаша.

2.1.10. «Үстерү» чараларын үткәрү тәҗрибәсен гомумиләштерә.

## 3. ТКК формалаштыру һәм аның эшен оештыру тәртибе

3.1. ТКК рәистән, ТКК рәисе урынбасарыннан, ТКК җаваплы сәркатибеннән һәм ТКК әгъзаларыннан тора.

ТКК инновацион үсеш өлкәсендәге экспертлардан торган вакытлы эксперт төркемнәре төзи ала. Эксперт төркемнәре составы ТКК рәисе тарафыннан раслана.

3.2. ТКК составы түбәндәгеләрнең вәкаләтле вәкилләреннән төзелә:

а) Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгы;

б) КУЭ субъектларына ярдәм инфраструктурасы оешмалары;

в) КУЭ субъектлары мәнфәгатьләрен чагылдыра торган коммерциясез оешмалар;

г) КУЭ субъектларына ярдәм итүче башка оешмалар.

3.3. ТКК составына әгъзаларның так саны кертелә. ТКК әгъзаларының минималь саны – 5.

3.4. ТКК белән ТКК рәисе җитәкчелек итә.

3.5. ТКК рәисе:

3.5.1. ТКК эшчәнлегенә турыдан-туры җитәкчелек итә.

3.5.2. ТКК әгъзалары һәм экспертлар арасында вазыйфаларны бүлә.

3.5.3. ТКК эшчәнлеген планлаштыра, аны алып бара, ТКК утырышының көн тәртибендәге мәсьәләләрне карау тәртибен билгели.

3.5.4. Утырышны үткәрү вакыты һәм урыны турында карар кабул итә.

3.5.5. Утырышның көн тәртибен раслый.

3.5.6. ТКК утырышлары беркетмәләрен, беркетмәләрдән өземтәләрне һәм ТКК башка документларын имзалый.

3.5.7. Кирәк булган очракта ТКК утырышында катнашу өчен дәүләт хакимияте органнары, иҗтимагый оешмалар вәкилләрен һәм мәнфәгатьле башка юридик һәм физик затларны чакыра.

3.6. ТКК рәисе булмаган очракта яки аның йөкләмәсе буенча ТКК рәисе бурычлары ТКК рәисе урынбасарына йөкләнә.

3.7. ТКК җаваплы сәркатибе:

3.7.1. ТКК утырышларын оештыра һәм эш алып бара.

3.7.2. ТКК эш планнары проектларын эшләүне тәэмин итә.

3.7.3. ТКК әгъзаларын аның эше, урыны, ТКК утырышын уздыру датасы, вакыты һәм көн тәртибе турында мәгълүмат белән тәэмин итә.

3.7.4. ТКК утырышларының беркетмәләрен рәсмиләштерә.

3.7.5. ТККның ТКҮ һәм КУЭ субъектларына ярдәм итүче башка оешмалар белән хезмәттәшлеген координацияли.

3.7.6. ТКК утырышлар беркетмәләрен исәпкә алуны һәм саклауны гамәлгә ашыра.

3.7.7. ТКК рәисе күрсәтмәсе буенча ТКК эшчәнлеге белән бәйле башка функцияләрне башкара.

3.8. ТКК әгъзалары:

3.8.1. Утырышның көн тәртибе буенча тәкъдимнәр кертә.

3.8.2. Утырышларда һәм аларда каралган мәсьәләләр буенча фикер алышуда катнаша.

3.8.3. ТКК карарларын әзерләүдә һәм кабул итүдә катнаша.

3.9. ТКК утырышлары зарурлык булганда, ләкин кварталга кимендә бер тапкыр уздырыла. Утырыш көн тәртибе, утырышны үткәрү урыны, датасы, вакыты һәм утырышның көн тәртибенә кагылышлы мәсьәләләр буенча материаллар күрсәтелгән, җаваплы сәркатип тарафыннан барлык ТКК әгъзаларына утырыш алдыннан кимендә 3 (өч) эш көне алдан җибәрелә.

3.10. ТКК утырышларын ТКК рәисе алып бара, ә ул булмаганда яки аның кушуы буенча – ТКК рәисе урынбасары.

3.11. ТКК утырышы, әгәр анда ТКК әгъзаларының кимендә яртысы катнашса, хокуклы санала. ТКК карары ачык тавыш бирү юлы белән гади күпчелек тавыш белән кабул ителә.

3.12. Һәр ТКК әгъзасы бер тавыш хокукына ия. ТКК әгъзалары мәсьәләләр буенча фикер алышканда һәм карарлар кабул иткәндә тигез хокукларга ия. Тавыш биргәндә тавышлар тигезләшкән очракта рәислек итүче зат тавышы хәлиткеч булып тора.

3.13. ТКК карарлары утырыш уздырылган көннән алып 3 (өч) эш көне эчендә беркетмә белән рәсмиләштерелә. Беркетмәләргә утырышка рәислек итүче зат һәм ТКК җаваплы сәркатибе кул куя.

3.14. ТКК әгъзалары үз фикерен язма рәвештә белдерергә мөмкин, ТКК җаваплы сәркатибе аны ТКК утырышы беркетмәсенә теркәп куярга тиеш, бу хакта күрсәтелгән беркетмәдә тиешле билге ясала.

3.15. ТКК составын үзгәртү турындагы тәкъдим теләсә кайсы ТКК әгъзасы тарафыннан кертелергә мөмкин. Үзгәрешләр кертү турындагы карар ТКК рәисе тарафыннан кабул ителә, ә ул булмаганда – ТКК рәисе урынбасары тарафыннан.

## 4. ТКК вәкаләтләре

4.1. ТКК үзенә йөкләнгән функцияләрне үтәү өчен түбәндәгеләргә вәкаләтле:

4.1.1. КУЭ субъектларына ярдәм итү мәсьәләләре буенча КУЭ субъектлары мәнфәгатьләрен чагылдыручы дәүләт хакимияте башкарма органнары, Татарстан Республикасындагы җирле үзидарә органнары, коммерциясез оешмалар, КУЭ субъектларына ярдәм итүче башка оешмалар белән хезмәттәшлек итәргә.

4.1.2. ТКК компетенциясенә керүче мәсьәләләрне карау өчен кирәкле документларны һәм материалларны билгеләнгән тәртиптә Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органнарыннан һәм Татарстан Республикасындагы җирле үзидарә органнарыннан соратырга һәм алырга.

4.1.3. КУЭ субъектларының җитештерү эшчәнлеген активлаштыру буенча Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органнары, иҗтимагый һәм җитештерү эшчәнлегендә катнашучы бүтән оешмалар каравына тәкъдимнәр кертергә.

4.1.4. Заказчыларның сатып алуларында катнашканда аларның көндәшлеккә сәләтле булу дәрәҗәсен арттыру максатларында КУЭ субъектлары үсешенә үтәргеч бирүгә юнәлдерелгән «үстерү» чараларын гамәлгә ашырганда КУЭ субъектларына ярдәм итү чараларын эшләргә (зарурлык булганда) һәм координацияләргә.

4.1.5. КУЭ субъектларына квалификацияле бәяләү үткәрүне оештыру буенча билгеләнгән тәртиптә тәкъдимнәр кертергә.

4.1.6. Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органнары, иҗтимагый органнар, мәнфәгатьле башка оешмалар вәкилләрен ТКК утырышларына чакырырга.

4.1.7. Алга таба Россия Федерациясе субъекты башкарма хакимияте органнарына, КУЭ субъектларына ярдәм итүче инфраструктура оешмаларына, КУЭ субъектларына ярдәм итүче башка оешмаларга «үстерү» чаралары турында мәгълүмат бирү максатларында заказчылардан аны системалаштыру һәм анализлау өчен мәгълүмат соратырга һәм алырга, түбәндәге өлешендә:

а) заказчыларның сыйфат менеджменты корпоратив системасы;

б) гамәлдәге тармак яисә корпоратив махсус таләпләр, шул исәптән продукцияне сертификацияләү (аттестацияләү) буенча; җитештерү, инвестиция программаларын һәм сатып алу планнарын анализлау (КУЭ субъектларыннан сатып алу өчен) нигезендә агымдагы һәм перспектив ихтыяҗлар номенклатурасы һәм күләмнәре буенча (КУЭ субъектларыннан сатып алу өчен) заказчыларны анализлау нигезендә;

в) инновацион үсеш программалары, инновацион продукциягә ихтыяҗ номенклатурасы һәм күләмнәре, инновацион продукция, югары технологияле продукция, дару чараларын сатып алу планнары;

г) өстенлекле продукция реестрына кертү буенча тәкъдимнәр (булган очракта).

4.1.8. КУЭ субъектын квалификацияле бәяләү нәтиҗәләрендәге белешмәләрне тикшерү максатларында яки ИҮК гамәлгә ашырганнан соң КУЭ субъекты тарафыннан хуҗалык эшчәнлеге алып барылган урынга чыгарга.